**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.03.2015 № 157

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 6 апрелендә теркәлде, № 2685

Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында
Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык
хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, дәүләтнең
гражданлык хезмәткәрләре үзләренең
керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм мөлкәт
характерындагы бурычлары турында,
шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган
балаларының керемнәре, чыгымнары, милке
һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында
мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфалар
исемлеген раслау турында

“Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законга туры китереп боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, дәүләтнең гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфаларның кушымта итеп бирелүче исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Шуны аңлатырга:

дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлеккә кертелгән вазыйфасын биләгән гражданин, дәүләт гражданлык хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тотышына карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу комиссиясе ризалыгы белән, оешмада хезмәт килешүе

шартларында вазыйфалар биләү һәм (яки) шушы оешмада бер ай дәвамында гражданлык-хокукый килешү (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында йөз мең сумнан артыграк бәягә эшләр башкару (бу оешмага хезмәтләр күрсәтү) хокукына ия, әгәр бу оешманы дәүләт идарә итүенең кайбер функцияләре элегрәк дәүләт гражданлык хезмәткәренең вазыйфасы (хезмәте) бурычларына кергән булса;

дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлеккә кертелгән вазыйфаларын биләгән гражданин, дәүләт гражданлык хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында, бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә) хезмәт килешүләре яки гражданлык-хокукый килешүләр төзегәндә, эшкә яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә үзенең соңгы эш урыны турындагы мәгълүматларны хәбәр итәргә тиеш;

дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлеккә кертелгән вазыйфаларын биләгән гражданинның, дәүләт гражданлык хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында, бу пунктның өченче абзацы белән күздә тотылган таләпләрне үтәмәве эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) әлеге гражданин белән төзелгән хезмәт килешүенең яки гражданлык-хокукый килешүнең өзелүенә сәбәп була.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында гражданнар, дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә, үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары һәм иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгәндә, Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 05.03.2014 ел, № 102 (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 26 мартында теркәлгән, № 2263) боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
“16” 03 2015 ел, № 157
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, дәүләтнең гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфалар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” категориясендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының эшләр идарәчесе;

Министрлыкның бүлек начальнигы;

Министрлыкның муниципаль районндагы (шәһәр округындагы) территориаль органы җитәкчесе;

Министрлыкның бүлек начальнигы урынбасары;

сектор мөдире;

Министрлыкның муниципаль районндагы (шәһәр округындагы) территориаль органы җитәкчесе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясендәге вазыйфасы – министр ярдәмчесе.

3. “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “белгечләр” һәм “тәэмин итүче белгечләр” категорияләрендәге вазыйфалары:

3.1. юридик бүлектә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант. Алар буенча вазыйфаи бурычларны үтәү контрольлек һәм күзәтчелек итү чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота;

3.2. дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч;

3.3. мәгълүмат технологияләре, автоматлаштырылган системаларны эшләтү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.4. планлаштыру, финанслау һәм хезмәткә түләү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.5. контроль-ревизия эше бүлегендә – әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч, 1 разрядлы белгеч;

3.6. дәүләт сатып алулары бүлегендә – әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.7. социаль яклау чаралары методологиясе бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.8. социаль регистрны формалаштыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.9. социаль яклау чаралары методологиясе бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.10. техник реабилитация чаралары бирү һәм шифаханә-курорт дәвасы бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.11. пенсиягә өстәмә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.12. социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.13. хезмәт базарын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүне күзәтү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.14. һөнәргә укыту һәм һөнәргә юнәлеш бирү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.15. хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.16. чаралар үткәрүне оештыру бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.17. социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын идарә итү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч эксперт;

3.18. административ-хуҗалык бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.19. җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.20. мобилизацияләү эше һәм гражданнар оборонасы секторында – – әйдәп баручы белгеч;

3.21. халык белән эшләү секторында – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант.